КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 10 март г.Казань № 142

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының санитария-эпидемияләргә каршы комиссиясе составы турында» 2013 ел, 17 июнь, 412 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 9 август, 555 нче, 2013 ел, 30 сентябрь, 703 нче, 2015 ел, 17 март, 158 нче, 2016 ел, 22 декабрь, 972 нче, 2018 ел, 25 май, 396 нчы, 2019 ел, 18 гыйнвар, 23 нче, 2020 ел, 11 февраль, 102 нче, 2022 ел, 27 июнь, 609 нчы, 2022 ел, 31 август, 933 нче, 2023 ел, 22 апрель, 513 нче, 2023 ел, 24 август, 1014 нче, 2024 ел, 29 март, 207 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының санитария-эпидемияләргә каршы комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан К.А.Нурмөхәммәтованы, Л.Ф.Хәбибрахманованы чыгарырга;

комиссия составына Садретдинов Марсель Альфред улын, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының хезмәтне саклау һәм экологик иминлек секторы мөдирен кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында» 2005 ел, 6 сентябрь, 438 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 гыйнвар, 21 нче, 2007 ел, 20 август, 399 нчы, 2007 ел, 6 декабрь, 690 нчы, 2009 ел, 25 май, 335 нче, 2009 ел, 24 декабрь, 871 нче, 2010 ел, 31 август, 688 нче, 2012 ел, 19 июнь, 523 нче, 2014 ел, 17 гыйнвар, 19 нчы, 2015 ел, 4 март, 133 нче, 2016 ел, 17

май, 320 нче, 2018 ел, 12 апрель, 237 нче, 2018 ел, 24 июль, 595 нче, 2018 ел, 28 август, 691 нче, 2019 ел, 21 июнь, 507 нче, 2019 ел, 5 сентябрь, 780 нче, 2020 ел, 20 гыйнвар, 13 нче, 2020 ел, 19 декабрь, 1160 нчы, 2022 ел, 27 апрель, 395 нче, 2022 ел, 16 декабрь, 1356 нчы, 2023 ел, 30 март, 381 нче, 2024 ел, 29 март, 204 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Д.В.Дороговны чыгарырга;

комиссия составына Фролова Елена Вилевнаны, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының халыкны физик тәрбияләү һәм физкультура-савыктыру эше бүлеге башлыгын кертергә;

Мостафина Софья Альфред кызы фамилиясен, исемен, атасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Галиева-Мостафина Софья Альфред кызы».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель, 346 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1157 нче, 2021 ел, 1 сентябрь, 801 нче, 2021 ел, 1 сентябрь, 801 нче, 2022 ел, 5 май, 417 нче, 2022 ел, 16 май, 446 нчы, 2022 ел, 7 июль, 651 нче, 2023 ел, 19 май, 609 нчы, 2023 ел, 6 октябрь, 1254 нче, 2024 ел, 15 март, 148 нче, 2024 ел, 04 июнь, 727 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан М.М.Бариевны, Р.А.Галәвовны, Р.А.Ратникованы, Е.Т.Сәгъдиеваны, Р.В.Черныхны чыгарырга;

комиссия составына Виниченко Владислав Валентиновичны, Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесен кертергә (килешү буенча);

Максим Владимирович Трущинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Баш идарә башлыгы урынбасары - Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча)».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие – Йолдызлык» еллык ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивален үткәрү турында» 2018 ел, 20 гыйнвар, 20 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 19 апрель, 263 нче, 2019 ел, 30 декабрь, 1277 нче, 2020 ел, 19 декабрь, 1157 нче, 2023 ел, 02 ноябрь, 1408 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Созвездие – Йолдызлык» еллык ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына, Зарипов Раушан Булат улы вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне

кертергә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин